Татарча التترية

# Ураза ике төргә бүленә:

**Мөстәһәб:** бу ике очрактан кала.

**Үәҗиб:** рамазан аенда һәм үтәлмәгән антның җәзасы;

**Нәрсә ул ураза?**

Ураза - ул таң атканнан алып кояш батканчыга кадәр ашау-эчүдән һәм башка уразаны боза торган нәрсәләрдән тыелып, Аллаһка гыйбәдәт кылу.

# Уразаның ике әркәне бар:

## 1 Ният

| Мөстәһәб булган уразага ният: | Фарыз булган уразага ният: |
| --- | --- |
| Мөстәһәб булган уразага ниятне көннең кайсы вакытында да ясау рөхсәт ителә, ләкин аңа кадәр ашамау шарт булып тора һәм әҗер-савап ният ясаган вакыттан башланачак. | Фарыз булган ураза тотуны төннән ниятләргә кирәк, ягъни таң атканчыга кадәр. Шулай ук рамазан аеның башында да ниятләү җитә. Ниятнең урыны йөрәктә һәм тавыш белә әйтү бидгать була. |

## 2 Уразаны боза торган нәрсәләрдән тыелу.



**Бу нәрсәләр уразаны боза:**

1-Белә торып ашау һәм эчү, әгәр онытылып ашалса, ураза бозылмый;
2-Якынлык кылу, әгәр уразада булган килеш якынлык кылына икән, аның җәзасы туктаусыз ике ай ураза тоту;
3-Мәнинең чыгуы;
4-Туклыклы уколлар сыман ашау-эчүне алмаштыра торган нәрсәләр;
5-Хиджама ясау; 6-Үзеңне үзең костыру;
7-Күрем көннәре сәбәпле, я инде бала туу сәбәпле кан чыгу.

**Ураза вакытында кайбер рөхсәт ителгән нәрсәләр:**

- Пешерүчегә ризыкны кабып карау;
- төкерекне йоту;
- юыну;
- хуш исләнү;
- суыну.

# Уразаның үәҗиб булуының шартлары:

| | |
| --- | --- |
| 1. Ислам; | 2.Акыл; |
| 3. Балигъ яшенә җитү, ләкин балигъ яшенә җитмәгән балаларны да ураза тотырга чакырырга кирәк; | |
| 4. Сәфәрдә булмау, чөнки сәфәрдә булучыга ураза үәҗиб түгел, ләкин авыр булмаса, шушы айның фазыйләтен ычкындырмас өчен, сәфәрдә дә уразасын тотса була; | |
| 5. Сау-сәламәт булу; | 6. Күрем көннәрендә булмау. |

**Ураза тотучыга харам булып тора:**

1 - Төкерекне авыз ачу нияте белән йоту;
2 - Уразаны бозуга китерә торган үбү;
3 - Тыелган сүзләр сөйләү һәм гамәлләр кылу;
4 - Әдепсезлек күрсәтү;
5 - Авыз ачмыйча ике көн рәттән ураза тоту.

**Уразада мәкрүһ булган нәрсәләр:**

1-Авыз-борынны чәйкаганда суны тирәнгә җибәрмәү;
2-Бер сәбәпсез ризыкны кабып карау.